ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.11.2023 ел Баулы шәһәре № 219

“Баулы муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү шартлары турында” 2018 елның 25 июнендәге 248 номерлы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 16 октябрендәге 1312 номерлы “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” карарына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1.“Баулы муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү шартлары турында” 2018 елның 25 июнендәге 248 номерлы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының карарына (Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 декабрендәге 487 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 318 номерлы, 2021 елның 2 ноябрендәге 195 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 245 номерлы, 2022 елның 4 июлендәге 125 номерлы, 2022 елның 30 декабрендәге 278 номерлы, 2023 елның 12 маендагы 118 номерлы, 2023 елның 24 августындагы 170 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә:

5 таблицада:

1 графада «Техник укыту бүлекләре (бюролары), оешмаларның кадрлар бүлекләре, производствода кадрлар әзерләү һәм квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче министрлыкларның (ведомстволарның) бүлекчәләре» юлларын, «министрлыклар (ведомстволар)» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары»

сүзләре белән алмаштырырга;

Баулы муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә:

4 таблицада:

1 графада «Техник укыту бүлекләре (бюролары), оешмаларның кадрлар бүлекләре, производствода кадрлар әзерләү һәм квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче министрлыкларның (ведомстволарның) бүлекчәләре» юлларын, «министрлыклар (ведомстволар)» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләре белән алмаштырырга;

Баулы муниципаль районы өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү шартлары турында Нигезләмәдә:

10 таблицада:

1 графада «Техник укыту бүлекләре (бюролары), оешмаларның кадрлар бүлекләре, производствода кадрлар әзерләү һәм квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче министрлыкларның (ведомстволарның) бүлекчәләре» юлларын, «министрлыклар (ведомстволар)» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы -
Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
социаль мәсьәләләр буенча
беренче урынбасары И.И. Хөснуллина